ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.07.2026 952 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру тәртибе турында» 2022 елның 30 сентябрендәге 1285 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары, Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алуга дәүләт хокукларын тәэмин итү өлешендә гражданнарның хокукларын яклау турында» 2013 елның 10 сентябрендәге 01-50-377/11-555 номерлы хаты,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә кергән хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары нигезендә һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмалары уставлары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының белем бирү учреждениеләрендә түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру тәртибе турында» 2022 елның 30 сентябрендәге 1285 номерлы карары белән расланган Түләүле хезмәтләр күрсәтүне оештырганда мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе җитәкчесенең якынча исемлегенә һәм бурычларын кертергә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Документ создан в электронной форме. № 952 от 07.07.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 1 из 2. Страница создана: 08.07.2026 09:22
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

«2. Белем бирү учреждениесе җитәкчесенә, расланган керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә хезмәткә түләүгә җибәрелә торган эшчәнлекнең эшкуарлык һәм башка кеременнән акчалар исәбеннән, югарыда күрсәтелгән бурычларны үтәгән өчен, түләүле (шул исәптән мәгариф) хезмәтләрнең барлык төрләре буенча аерым бер чорда керә торган акчаларның гомуми суммасыннан 10 % күләмендә айлык өстәмә түләү билгеләргә;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4C332AC224D0671AE6BDE7AE77479904

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 02.02.2026 до 28.04.2027

Э.Р. Әхмәдиева